«2018 елга һәм 2019 һәм 2020 еллар план чорына Зеленодольск муниципаль районы бюджеты турында» Зеленодольск муниципаль районы Советы карары проекты буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләре хакында
**бәяләмә**

Гавами тыңлаулар 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы, Зеленодольск муниципаль районы Башлыгының «Зеленодольск муниципаль районы Советының 2018 елга һәм 2019 һәм 2020 еллар план чорына бюджеты турында» Зеленодольск муниципаль районы Советының карары проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү хакында» 2017 елның 16 ноябрендәге 225 номерлы карары нигезендә үткәрелде.

Үткәрү вакыты һәм вакыты: 2017 елның 6 декабрендә 16.00 сәгатьтә;

Үткәрү урыны:Зеленодольск шәһәре, Ленин урамы, 46 нчы йорт адресы буенча, Горький исемендәге мәдәният, сәнгать һәм халык иҗаты үзәге.

Халыкны таныштыру өчен 2018 елга һәм 2019 һәм 2020 еллар план чорына Зеленодольск муниципаль районы бюджеты проекты Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru ) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (www.zelenodolsk.tatarstan.ru) , Зеленодольск шәһәрендә - Горький исемендәге мәдәният, сәнгать һәм халык иҗаты үзәгендә (Ленин ур., 46 нчы йорт, китапханә уку залы), Ф.Шәфигуллин исемендәге 42 нче милли – туган якны өйрәнү китапханәсе-филиалы- «Зеленодольск муниципаль районы үзәкләштерелгән китапханә системасы» МБУ (М. Жуков урамы, 7 нче йорт, китапханә уку залы). урнаштырылды.

Зеленодольск муниципаль районы Советының «2018 елга һәм 2019 һәм 2020 еллар план чорына Зеленодольск муниципаль районы бюджеты турында» карары проекты буенча гавами тыңлаулар уздыру өчен кирәкле барлык процедуралар тиешенчә үтәлде.

Массакүләм мәгълүмат чараларында басылып чыкканнан соң һәм тыңлаулар үткәрү көнендә фикер алышына торган мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кермәде.

Зеленодольск муниципаль районы Башлыгының 2017 елның 16 ноябрендәге 225 номерлы карары белән билгеләнгән һәм 2017 елның 6 декабрендә уздырылган гавами тыңлаулар нәтиҗәләре буенчагавами тыңлауларда катнашучылар Зеленодольск муниципаль районының 2018 елга һәм 2019 һәм 2020 еллар план чорына бюджет проектын хупладылар һәм аны Зеленодольск муниципаль районы Советына карап тикшерүгә тапшырырга тәкъдим иттеләр.

А. В. Старостин,
рәислек итүче

Ф. Ф. Шамгунов,
Секретарь

Зеленодольск муниципаль районы Советының «2018 елга һәм 2019 һәм 2020 еллар план чорына Зеленодольск муниципаль районы бюджеты турында» карары проекты буенча гавами тыңлаулар
**беркетмәсе**

Зеленодольск шәһәре 2017 елның 6 декабре
Ленин ур., 46 й. 16.00 сәг.
Горький исемендәге мәдәният, сәнгать һәм халык иҗаты үзәге, утырышлар залы

Рәис:

Старостин Александр Владимирович - Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары (алга таба - ЗМР Башкарма комитеты)

Гавами тыңлаулар беркетмәсен алып бару өчен түбәндәге составта секретариат сайланган:

Шамгунова Фәридә Фәрит кызы - ЗМР Башкарма комитетының социаль-икътисадый фаразлау һәм анализ бүлеге башлыгы урынбасары

Чыгыш ясаучылар:

1. Стерякова Анастасия Сергеевна - ЗМР Башкарма комитетының социаль-икътисадый фаразлау һәм анализ бүлеге башлыгы «Зеленодольск муниципаль районының 2017 елгы социаль-икътисадый үсеш нәтиҗәләре һәм 2018-2020 елларга социаль-икътисади үсеш фаразының төп күрсәткечләре турында» мәгълүмат бирде.
2. Дёгтева Ольга Павловна - «Зеленодольск муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» МУ җитәкчесе «Зеленодольск муниципаль районының 2018 елга һәм 2019 һәм 2020 еллар план чорына бюджеты турында» хәбәр итте.
3. Зеленодольск муниципаль районы Советының документлар әйләнеше һәм гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү бүлеге башлыгы тарафыннан гражданнардан фикер алышу мәсьәләсе буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр килмәве турында хат тапшырылды.

Секретариатка запискалар килмәде.

Рәис А.В.Старостин

Ф.Ф.Шамгунова
5-53-38